**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Алабуга районының Олы Шүрнәк авылы;

Яңа Чишмә районының Горшково авылы;

Тәтеш районының Лаптевка авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Әлки районының Базарлы Матак авылындагы Нәби Дәүли урамы;

Апас районының Апас шәһәр тибындагы поселогында М. Крымов урамы;

Әтнә районының Ключи-Сап авылындагы Тукай урамы;

Буа районының Кайбыч авылындагы Беренче Май урамы;

Биектау районы Бөреле җәнлек совхозы поселогындагы Светлая урамы;

Зәй шәһәрендәге 8 Март урамы;

Питрәч районының Надеждино авылындагы Яңа урам;

Саба районының Тимершык авылындагы Пушкин урамы;

Саба районының Туктар авылындагы Маркс урамы;

Спас районының Татар Такталысы авылындагы Үзәк урам;

Азнакай районы Чемодурово авылы янындагы «Союз-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясе.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 20 гыйнварындагы ПУ-32 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының Горшково авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 20 гыйнварындагы ПУ-38 номерлы Указының 1 пункты «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче, дүртенче, бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлары.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 23 март
№ ПУ-306